СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 6-27 «29» июнь 2018 ел

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 2013 елның 8 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы турында» 6-25 номерлы карары;
- 2014 елның 28 маендагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» 9-31 номерлы карары;
-2014 елның 19 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» 6-35 номерлы карары;
- 2015 елның 18 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» 4-4 номерлы карары;
-2016 елның 3 октябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 8-11 номерлы карары;
- 2017 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» 9-16 номерлы карары;

- 2017 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 4-20 номерлы карары.

3. Әлеге карарны һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4.«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең әлеге карарын һәм Уставын, дәүләт теркәвенә алганнан соң, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов